**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЯҢА ЧИШМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 24 нче сентябреннән № 37-141

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 33-98 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

1998 елның 31 июлендәге 146-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 33-98 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 08.09.2015 №41-128; 27.10.2015 №3-12; 14.11.2018 №36-114; 23.09.2019 №48-162; 20.03.2021 № 7-28 карарлары редакциясендә) (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 4 өлешендәге 2 пунктын 31.12.2027 елга кадәр туктатырга;

1.2. Карарның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйданы булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата 1,2 % ».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 31.12.2027 елга кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы В.М. Козлов